| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>СТАРОЧУКАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ЧОКАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

# РЕШЕНИЕ

24 август 2016ел № 12/1

Җир салымы турында

Россия Федерациясе Салым кодексы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чокалы авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге советы карар чыгарды:

1. «Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чокалы авыл җирлеге советы карарын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми игълан ителгән көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карар үз көченә кергәч, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чокалы авыл җирлеге советы карарының үз көчен югалтуын таныргa:

1) «Җир салымы турында» 2014 елның 20 ноябрендщге 43/1 номерлы;

2) «Җир салымы турында» 2015 елның 10 августындагы 54/3номерлы;

3) «Җир салымы турында карар кабул итүгә үзгәреш кертү хакында» 2015 елның 13 октябрендәге 2/5 номерлы (2015 елның 10 августындагы 54/3 номерлы редакциясендә)».

Глава Старочукалинского
сельского поселения: Р.Р.Низамутдинов

Кушымта
Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы Светының 2016 елның 26 августындагы №16/1 карары белән расланган

Җир салымы турында

1 статья. Гомуми нигезләмәләр

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нормалары нигезендә әлеге карар белән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чокалы авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләүгә җир салымы (алга таба - салым) билгеләнә һәм гамәлгә кертелә.

2 статья. Салым ставкалары

Салым ставкалары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

1) торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,1%;
2) шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, яшелчәчелек һәм терлекчелек, шулай ук дача хуҗалыгы өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,1%-ын;
3) җир кишәрлекләренең торак пунктлары чикләреннән читтә урнашкан җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 1,5 %ы: сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшырулар, телевидение, информатика җирләре, космик эшчәнлекне тәэмин итү өчен җирләр, оборона җирләре, оешмалар һәм учреждениеләр карамагындагы башка махсус билгеләнештәге җирләр;
4) башка җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясеннән 1,5 %;
5) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә кертелгән һәм торак пунктларда авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган авыл хуҗалыгы зоналары составындагы җирләргә карата кадастр бәясенең 0,3 проценты;
6) 1-3 категориядәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,05 %ы.

3 статья. Хисап чоры

Салым түләүчеләр - оешмалар өчен хисап чорлары дип билгеләргә, беренче квартал, икенче квартал һәм календарь елның өченче кварталы танылa.

4 статья. Салым ташламалары

1. Россия Федерациясе Салым кодексының 389 статьясында каралган очраклардан тыш, граждан күмүләре белән мәшгуль авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренә карата оешмаларны, учреждениеләрне җир салымы түләүдән азат итәргә.

2. Бюджет учреждениеләренең, хакимият органнарының һәм идарәнең җир кишәрлекләренә, җирле үзидарә органнарының җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясеннән 1,0 % күләмендә җир салымы ставкасын билгеләргә.

5 статья. Салым буенча салым һәм аванс түләүләрен түләү тәртибе һәм сроклары.

Салым түләүчеләр - оешмалар өчен, салым түләү җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең 1/4 күләмендә, беренче, икенче һәм өченче кварталлар узганнан соң салым чоры булып торучы елның 1 гыйнварына 5 майда, 5 августта, 5 ноябрьдә аванс түләүләре белән башкарыла.

Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым түләү срогы үткән салым чорыннан соң килүче елның 15 февралендә билгеләнә.

6 статья. Салым түләүчеләр тарафыннан салым салына торган базаны киметүгә хокукны раслый торган документлар тапшыру тәртибе һәм сроклары Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә салым базасын киметү хокукын раслый торган документлар салым түләүчеләр тарафыннан салым салу объекты буларак таныла торган җир кишәрлегенең урнашкан урыны буенча салым органына узган салым чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр тапшырыла.

7 статья. Җир кишәрлекләренең кадастр хакын салым түләүчеләргә җиткерү тәртибе.

Җирләрне дәүләт кадастр бәяләвен үткәрү нәтиҗәләре буенча, календарь елның 1 гыйнварына торышы буенча җир кишәрлекләренең кадастр бәясе салым түләүчеләр игътибарына, агымдагы елның 1 мартыннан да соңга калмыйча, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә җиткерелергә тиеш.».